БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _______ 2020 г. № _____

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында**

«2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында» 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Россия Федерациясе Президентының боерыгы, «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында» 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы Татарстан Республикасы Президентының боерыгы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2015 елның 9 июнендәге 264 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында Нигезләмәдә билгеләнгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына белешмәләр бирү вакытын 2020 елның 1 августына кадәр (1 августны кертеп) озайтырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы рәсми

сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе                                                  А.Ф. Хәйретдинов